ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (Х өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:
а) 1 өлештә:
«в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«в) мөрәҗәгать итүче гражданның гаилә составын раслый торган документларның (граждан хәле актларын дәүләт теркәве турында «Граждан хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән таныклыклар йә гаилә әгъзасы буларак тану турында, уллыкка (кызлыкка) алу хакында суд карары (билгеләмәсе) күчермәләре;»;
«ж» пунктчасында «һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган мәгълүматларны бирүне» сүзләрен төшереп калдырырга;
түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасын өстәргә:

«з) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокукны билгеләүче документлар.»;

б) 2 өлешнең «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) мөлкәт хокукларын теркәүне гамәлгә ашыручы органнардан гражданнарның салым салынырга тиешле күчемсез һәм күчемле мөлкәткә милек хокукында ия булуларының хокукый нигезләренраслый торган документларның күчермәләре;»;

в) $4^1$ өлештә:

беренче абзацта «а», «б», «в» һәм «г» (икенче абзацтан тыш) пунктчаларында» сүзләрен «а» , «б», «г» (икенче абзацтан тыш) һәм «з» пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «1 өлешендәге» сүзләреннән соң «в» пунктчасында (гражданнар тарафыннан тапшырыла торган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 3, $3^1$ һәм 12 пунктларында каралган документлардан тыш), «г» пунктчасының икенче абзацында,» сүзләрен өстәргә;

2) 8 статьяның 8 өлешендә «билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен төшереп калдырырга, «чиратлылык турында» сүзләреннән соң «үзе билгеләгән тәртиптә» сүзләрен өстәргә;

3) 10 статьяның «д» пунктчасындагы дүртенче абзацында «мәгариф оешмаларында укучыларга,» сүзләреннән соң «фәнни һәм» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 5 пунктындагы «в» пунктчасында «мәгариф оешмаларында укучыларга,» сүзләреннән соң «фәнни һәм» сүзләрен өстәргә;

2) 14 статьяның 1 өлешендә «һәм Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында булган белешмәләрне бирүне» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 16 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) мөлкәт хокукларын теркәүне гамәлгә ашыручы органнардан гражданнарның салым салынырга тиешле күчемсез һәм күчемле мөлкәткә милек

хокукында ия булуларының хокукый нигезләрен раслый торган документларның күчермәләрен;»;

4) 17 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мөрәҗәгать итүче гражданның гаилә составын раслый торган документларның (граждан хәле актларын дәүләт теркәве турында «Граждан хәле актлары турында» 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән таныклыклар йә гаилә әгъзасы буларак тану турында, уллыкка (кызлыкка) алу хакында суд карары (билгеләмәсе) күчермәләре;»;

б) 2 өлештә «1, 2 һәм 3 пунктларында» сүзләрен «1 һәм 2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга, «5 өлешеннән» сүзләрен «6 өлешеннән» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлештә «1 өлешендәге» сүзләреннән соң «3 пунктында (гражданнар тарафыннан тапшырыла торган «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 3, $3^1$ һәм 12 пунктларында каралган документлардан тыш),» сүзләрен өстәргә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, үз көчләренә керүнең әлеге статья белән башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты һәм 2 статьясындагы 1 пункты 2021 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3. Әлеге Закон үз көченә кергән көннән «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 4 өлеше һәм «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 6 өлеше нигезләмәләре кулланылмый.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 22 июнь
№ 41-ТРЗ